# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«12 » февраль 2021 ел № 6/1

**Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 мартындагы 33/2 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында**

2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Федераль казначылык идарәсе уртак коллегиясенең 2021 елның 4 январендәге ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 мартындагы 33/2 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмә»нең 3.3 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

« 3.3. Яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алу өчен, мөрәҗәгать итүче авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә билгеләнгән форма буенча (1 нче кушымта) хат-гариза бирә, анда утыртмаларның саны, исеме, аларның торышы, чикләнгән кисү үткәрелү урыны һәм аны нигезләү күрсәтелгән булырга тиеш. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

- шәхесне таныклый торган документлар;

- вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эшләсә);

- киселергә тиешле яшел утыртмаларны күрәтеп, якындагы корылмаларга яисә башка ориентирларга кадәр кишәрлек схемасы;

- җир кишәрлеге Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче һәм хокукны раслаучы документларның таныкланган күчермәләре;

- биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел утыртмаларны кисү башкарылган очракта, расланган проект документациясе;

- территорияләрнең хуҗалары белән яшел утыртмаларны кисү һәм күчереп утырту шартларын килештерү;

- утыртмаларны утыртканда яисә күчереп утыртканда, җир эшләрен уздыруга ордер ачып, инженерлык челтәрләре вәкилләре белән килештерү.

3.3.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты ведомствоара запрослар нигезендә, шул исәптән электрон формада, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында , авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, белешмәләр ала.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе О.А. Гончарова